СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 13-6 от «08» апрель, 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмә турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).
2. Карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының pravo.tatarstan. ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

Мамадыш
муниципаль районы
Советының
08.04.2016 ел, № 13-6 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмәдә муниципаль хезмәткәрләр, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба-хәбәрнамә).

3. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә 1 нче кушымтадагы форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрәләр.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе муниципаль район Башлыгына 2 нче кушымтадагы форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрәләр.

5. Авыл (шәһәр) җирлеге башлыгы муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә 3 нче кушымтадагы форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

6. Муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе, муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе адресына килгән хәбәрнамәләр карау өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия хәбәрнамәләр, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар җибәргән затлардан

билгеләнгән тәртиптә алырга һәм федераль дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр җибәрергә хокуклы.

7. Мөрәҗәгатьләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар комиссия утырышына тапшырыла, ул комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә үткәрелә.

Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән запрослар җибәрелгән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып 45 көн эчендә муниципаль район башлыгына, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә яисә муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артмаска тиеш.

8. Комиссия белдерүләрне Мамадыш муниципаль районы Советының 18.11.2014 ел карары белән расланган комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карый һәм алар буенча карарлар кабул итә. 9-34 номерлы " Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында Нигезләмәне раслау хакында» һәм кабул ителгән карарны муниципаль район башлыгына, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә, муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

9. Муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе, муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе комиссия тарафыннан белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмавын таныргa;

б) хәбәрнамә юллаган затның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип таныргa;

в) хәбәрнамә юллаган зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген таныргa.

10. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы Рәисе яки муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрә яки чаралар

күрүне тәэмин итә йә хәбәрнамә җибәргән Затка мондый чаралар күрергә тәкъдим итә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе, муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын кулланалар.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районында
муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче
затлар тарафыннан вазыйфаи
бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр
конфликтына китерә торган
яисә китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксыну барлыкка килү т
урында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

___________________________
(танышу турында билге)

_________________________________
(вәкиллекле орган рәисенә, Башкарма комитет
җитәкчесенә___________________
Татарстан Республикасы муниципаль районының) (кирәклесен сайларга))
кемнән

_________________________________
(Ф.И.О., вазифа)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым тууы турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: _________________________________________________________

______________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яисә йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: _______________________________________

______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ________________________________________________________

______________________________________________________________________

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районының әлеге белдерүен караганда (кирәклесен ассызыкларга).

«___»_______________ 20__ ел _________________________

_________________________

(хәбәрнамә җибәрүченең имзасы (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районында
муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче
затлар тарафыннан вазыйфаи
бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр
конфликтына китерә торган
яисә китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксыну барлыкка килү т
урында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

___________________________
(танышу турында билге)

Татарстан Республикасы
______________________________
муниципаль районы Башлыгына
кемнән
________________________________
(Ф.И.А и., вазифа)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым тууы турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: ___________________________________________________________
_________________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яисә йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________
_________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ___________________________________________________
_________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмимим)________________________ Татарстан

Республикасы муниципаль районының әлеге белдерүен караганда (кирәклесен ассызыкларга).

«___»______________ 20__ ел ________________________ ______________________

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаның расшифровкасы )

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районында
муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче
затлар тарафыннан вазыйфаи
бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр
конфликтына китерә торган
яисә китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксыну барлыкка килү т
урында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

______________________
(танышу турында билге)

______________________
муниципаль районының вәкиллекле органы рәисенә
кемнән:
______________________
(Ф.И.А и., вазифа)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган
яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
хәбәрнамә

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым тууы турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: ______________________________________________

______________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яисә йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: ______________________________

______________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________

______________________________________________

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмимим)______________________ Татарстан Республикасы муниципаль районының әлеге белдерүен караганда (кирәклесен ассызыкларга).

«___»_______________ 20__ ел _________________________
______________________

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы (имзаның расшифровкасы)